**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.11.2023** № **04-05-105**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 маддәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 нчы елның 6 нчы маенда чыгарылган «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында» 393 номерлы Карарын гамәлгә ашыру максатыннан боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү Тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Рәис Р.Н.Сабиров

Татарстан Республикасының
Сатып алулар буенча дәүләт
комитетының 2023 нче елның 10
нчы ноябрендә чыгарылган 04-05-
105 номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү Тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатыннан эшләнде.

2. Дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигезләр:

2.1. Физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүченең үлеме яисә анын Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе;

2.2. Шәхси эшмәкәрне – 2002 нче елның 26 нчы октябрендә чыккан «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 127-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә – бурычлы затның милке җитмәү сәбәпле түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч өлешендә – Татарстан Республикасы бюджетына түләүчене банкрот дип тану.

Банкротлык фактын раслаучы документ булып конкурс производствосын тәмамлау яисә шәхси эшмәкәр булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты, шулай ук шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең, аны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителү сәбәпле, шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктату хакында белешмәләр булган документ санала;

2.3. 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычлар белән бәйле өлешендә, шәхси әшмәкәр булмаган гражданинны банкрот дип тану.

2.4. Оешманың милке җитмәү сәбәпле һәм (яки) әлеге оешманы оештыручылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түли алмау сәбәпле түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар өлешендә оешманы – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүчене бетерү;

2.5. Җәза буларак штрафка тартылган хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турында акт куллану яки суд тарафыннан шул нигездә бюджет керемнәре администраторының Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалтуы турында карар кабул ителү;

2.6. 2007 нче елның 2 нче октябрендә чыгарылган «Башкарма производство турында» 229-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы Федераль закон) 46 нчы маддәсенең 1 нче бүлегенең 3 нче яисә 4 нче пунктында каралган нигездә суд приставы-башкаручы тарафыннан эшне тәмамлау турында һәм башкарма документны түләтүчегә кире кайтару турында карар чыгару, бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт үтсә, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә, бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаганда;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда;

2.7. Юридик затны теркәүче орган карары буенча юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру, бу юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә белән раслана, һәм 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 нчы маддәсенең 1 нче бүлегенең 3 нче яки 4 нче пунктында каралган нигездә түләтүчегә башкарма документны кире кайтару белән бәйле рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы – оешманың милке җитмәү сәбәпле һәм (яки) әлеге оешманы оештыручылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар өлешендә.

3. Тәртипнең 2 нче пунктында каралган очраклар белән беррәттән, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазифа башкаручы зат тарафыннан, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турында карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылган булса, түләнмәгән административ штрафларны түләттерү өметсез дип таныла.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

4.1. Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләү өчен исәпләнгән бурычлар турында отчёт документларыннан өземтәләр;

4.2. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында Дәүләт комитеты белешмәләре;

4.3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүченең үлеме яисә анын Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүен раслаучы документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс производствосын тәмамлау яисә шәхси эшмәкәр булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты, шулай ук шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең, аны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителү сәбәпле, шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктату хакында мәгълүматлар булган документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс производствосын тәмамлау яисә гражданинның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.3 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманы бетерү белән бәйле эшчәнлекне туктату турында мәгълүматны үз эченә алган документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

җәза буларак штрафка тартылган хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторының Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалтуга нигезләнгән суд акты (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 нчы маддәсенең 1 нче бүлегенең 3 нче яисә 4 нче пунктында каралган нигездә суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында һәм башкарма документны түләтүчегә кире кайтару турында карар (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.6 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

бурычлыны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылу яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылу турында суд акты (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.6 пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән очракта);

юридик затны – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүчене теркәүче орган карары буенча юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында мәгълүматны үз эченә алган документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турында карарны үтәүне туктату турында карар (Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән очракта).

5. Бурычны түләттерүне өметсез дип тану эшен оештыру максатыннан, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия әгъзалары составында Татарстан Республикасы Дәүләт сатып алулар комитеты (алга таба – Комиссия) белән идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны исәптән чыгару буенча Комиссия төзелә. Комиссия биш кешедән тора. Комиссиянең шәхси составы Дәүләт комитеты рәисенең (аның вазифаларын башкаручы затның) боерыгы белән раслана.

6. Комиссия рәисе:

Комиссия эше белән идарә итә;

Комиссия утырышлары үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан Комиссиянең җаваплы секретарен билгели.

Рәис булмаганда аның функцияләрен комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссиянең җаваплы секретаре:

Комиссия эшләрен алып баруны оештыра;

Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат бирә;

Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

8. Комиссия утырышлары кирәк саен уздырыла, ләкин кимендә елга бер тапкыр.

9. Тәртипнең 4 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану нигезләрен раслаучы документлар пакеты Дәүләт комитетына Тәртипнең 2 нче яки 3 нче пунктында каралган очракның килеп чыгуы турында мәгълүмат кергән көннән алып биш эш көне эчендә әйдәп баручы киңәшче - бухгалтер тарафыннан формалаштырыла. Документлар, кабул ителгән көннән алып, 30 календарь көн эчендә Комиссиягә каралуга җибәрелә.

10. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән җыелышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта председательлек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану мәсьәләсен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

әлеге Тәртипнең 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документлар булган очракта Татарстан

Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерүне өметсез дип танырга;

әлеге Тәртипнең 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булмаган очракта бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип танудан баш тартырга.

Комиссиянең бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип танудан баш тарту турында карары әлеге Тәртип нигезендә бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану мәсьәләсенең Комиссия тарафыннан яңадан каралуына комачауламый.

11. Комиссия карары Комиссия утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта));

салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешма салым түләүченең исәпкә кую сәбәбе коды (физик зат салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта));

бурыч барлыкка килгән Татарстан Республикасы бюджетына түләү турында мәгълүматлар;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн.

Акт ике данәдә төзелә һәм утырышта председательлек итүче һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Комиссия тарафыннан төзелгән акт имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан раслана.

_______________________